КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 октябрь г.Казань № 1100

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 648 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «тиешле» сүзен «шул исәптән тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләренә түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен Тәртип нигезендә төзергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына:

Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштырганда әлеге карарны кулланырга;

Тәртип нигезендә чираттагы финанс елына муниципаль учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырырга.»;

әлеге карар белән расланган Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибендә:

5 пунктның «а» пунктчасының өченче абзацында «тиешле» сүзен «шул исәптән тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5[1] пункт өстәргә:

«5[1]. Хезмәт хакын чираттагы финанс елына түләүгә җибәрелә торган керемнәр фаразы, Исемлек нигезендә керемнәрдән тыш, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр исәбенә Тәртипкә кушымта нигезендә төзелә.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә;

әлеге карар белән расланган акчалар максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегендә:

исемендә «тиешле» сүзен «шул исәптән тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 24 һәм 25 пунктлар өстәргә:

«24. Төп чараларны гамәлгә ашырудан алынган керемнәр.

25. Милекне арендага тапшырудан алынган керемнәр мондый мөлкәтне тотуга чыгымнар күләме өлешендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә планлы күрсәткечләр формалаштыру тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нче карары редакциясендә)

Хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре (казна учреждениеләреннән тыш) тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр өлеше, шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш

| Т/с | Ведомство буйсынуында Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре булган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре исеме | Хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр өлеше |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | кимендә 75% |
| 2. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | |
| 3. | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | |
| 4. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | |
| 5. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | |
| 6. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | |
| 7. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
| 8. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | |
| 9. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 10. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | |
| 11. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | |
| 12. | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 13. | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | |
| 14. | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты | |
| 15. | «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурслары сыйфатын һәм рациональ файдалануны тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе | |
| 16. | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе | |
| 17. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | |
| 18. | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы* | кимендә 50% |
| 19. | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы* | |
| 20. | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы * | |
| 21. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе* | |
| 22. | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы* | |
| 23. | «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт учреждениесе* | |

*Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр исәбенә чираттагы финанс елына хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр фаразы чираттагы финанс елына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып агымдагы финанс елына фараздан түбән булмаган күләмдә формалаша.

| Муниципаль учреждениеләр тарафыннан хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган, шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрнең тәкъдим ителә торган өлеше Т/с | Тармак исеме | Хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр өлеше |
|---|---|---|
| 1. | Мәгариф | кимендә 75% |
| 2. | Яшьләр сәясәте | |
| 3. | Башка тармаклар | |
| 4. | Мәдәният* | кимендә 50% |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Спорт* | |

*Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр исәбенә чираттагы финанс елына хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр фаразы чираттагы финанс елына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып агымдагы финанс елына фараздан түбән булмаган күләмдә формалаша.